ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.04.2020 г. Заинск №168

**«2020 елда Зәй муниципаль районы бюджетының өстәмә керем чыганакларын эзләү, бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, акчаларны экономияле тоту, түләүләр буенча бурычларны киметү буенча муниципаль программаны раслау турында»**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 34 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2020 елда Зәй муниципаль районы бюджетының өстәмә керем чыганакларын эзләү, бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, акчаларны экономияле тоту, түләүләр буенча бурычларны киметү буенча муниципаль программаны расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә һәм

эшкуарлыкка ярдәм буенча урынбасарына (М.И. Захарова) һәм Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (П.А. Байрашев) (килешү буенча) йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**

Юрист
П.А. Байрашев
3 22 73

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
16.04.2020 ел
168 номерлы карарына
кушымта

# 1. 2020 елда Зәй муниципаль районы бюджетының өстәмә керем чыганакларын эзләү, бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, акчаларны экономияле тоту, түләүләр буенча бурычларны киметү буенча муниципаль программаның ПАСПОРТЫ

| **Программаның аталышы** | **2020 елда Зәй муниципаль районы бюджетының өстәмә керем чыганакларын эзләү, бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, акчаларны экономияле тоту, түләүләр буенча бурычларны киметү буенча муниципаль программа** |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез | "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>Россия Федерациясе Бюджет кодексының 34 статьясы |
| Программаның координаторы | Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы |
| Муниципаль заказчы | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы<br>Зәй муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы |
| Максат һәм бурычлар | Бюджет чараларын оптимальләштерүгә һәм аларны сарыф итүдә нәтиҗәлелекне арттыруга, муниципаль милекне файдалануның нәтиҗәлелеген арттыруга, салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны киметү, өстәмә, шул исәптән бюджетны тулыландыруның бюджеттан тыш чыганакларын үстерүгә юнәлдерелгән яңа механизмнарны эшләү һәм куллану |
| Тормышка ашыру вакыты | 2020 ел |
| Программаны үтәүчеләр | Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары<br>Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр<br>Муниципаль бюджет учреждениеләре<br>Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы (килешү буенча)<br>Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад |

| | |
|---|---|
| | бүлеге |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны тормышка ашыру өчен бюджет чараларын файдалану күздә тотылмый |
| Программа үтәлешенә контроль | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы |
| Программаны тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре | Бюджет учреждениеләре тарафыннан чыгым йөкләмәләрен һәм хезмәткәрләр санын арттырмыйча муниципаль биремнәрне үтәү<br>Конкурентлы сатып алулар күләмнәренең сан һәм сыйфаты үсеше<br>Коммуналь хезмәтләргә чыгымнарны киметү<br>Өстәмә объектларны һәм чыганакларны хуҗалык әйләнешенә кертү һәм недоимканы киметү исәбенә бюджетка керемнәрнең артуы |

## 2. Икътисадта агымдагы хәл һәм аның бюджет тотрыклылыгына йогынтысы

Дөньякүләм базарларда волотильлек белән бәйле икътисадның тотрыксызлыгы, короновирус инфекциясе таралуга бәйле рәвештә чикләү чаралары куллану чорында җитештерелгән продукция күләме сизелерлек кими, хезмәткәрләрнең мәшгульлеге түбәнәя. Һәм, нәтиҗә буларак, бюджетка һәм бюджеттан тыш фондларга керемнәр кими, шул исәптән җирле бюджетларга да.

2020 елның II кварталында, җитештерү күрсәткечләре, продукция эшләп чыгару күләмнәре кимү, күпчелек тармакларда эшләүчеләр санын киметергә мәҗбүр булуны исәпкә алып, Зәй муниципаль районының берләштерелгән бюджетына керемнәрнең кимүе фаразлана.

Шул ук вакытта социаль характердагы чыгымнарны тулысынча финанслауны тәэмин итү бурычы да саклана.

Бу чорда бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, бюджетны тулыландыруның өстәмә мөмкинлекләрен эзләү зарур.

Программа бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану принцибын үтәүгә юнәлдерелгән. Бюджет процессында катнашучылар, бюджетның расланган параметрлары үтәлмәү куркынычын исәпкә алып, нәтиҗәләргә аз күләмдә акча кулланып ирешү зарурлыгыннан чыгып эш итәргә тиеш.

## 3. Программаның төп максаты, бурычлары һәм аны тормышка ашыру сроклары

3.1. Программаның төп максатлары булып бюджет средстволарын оптимальләштерүгә һәм аларны тотуда нәтиҗәлелекне арттыруга, шулай ук муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрүгә, 2020 елда Зәй муниципаль районы бюджетының баланслылыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән яңа механизмнар эшләү һәм алардан файдалану тора.

3.2. Программаның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Зәй муниципаль районы бюджетының баланслылыгын тәэмин итү һәм Зәй муниципаль районы бюджет системасының тотрыклылыгын ныгыту;

2) Зәй муниципаль районы бюджет чыгымнарының функциональ эффектлылыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыру;

3) Зәй муниципаль районы бюджеты чыгымнарын экономияләүнең эчке резервларын ачыклау;

4) Зәй муниципаль районы өчен өстенлекле мәсьәләләрне хәл итүгә ресурсларны яңадан бүлү һәм туплау;

5) бюджетның кичектерелгән кредит бурычлары барлыкка килүгә юл куймау;

6) Зәй муниципаль районының финанс-бюджет системасында идарә итү функцияләренең нәтиҗәлелеген арттыру

3.3. Программаны тормышка ашыру вакыты-2020 ел.

## 4. Программаның үтәлешен характерлаучы максатчан күрсәткечләр

Исәп-хисап

| № п/п | Максатчан күрсәткечнең исеме | Исәп-хисап формуласы | Критерийлар (2020 елда максатчан индикаторның күрсәткече) |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Расланган бюджет чыгымнары күләменең алдагы ел чыгымнары күләменнән абсолют тайпылу проценты, % | $U_p = \lvert A_{p.2} - B_{p.1} \rvert / B_{p.1} * 100\%$, где $A_{p.2}$ - чираттагы финанс елына башта расланган бюджет чыгымнары күләме, $B_{p.1}$ - хисап финанс елында бюджет чыгымнары күләме | < 10 % |
| 2. | Муниципаль хезмәткәрләр санын арттыруга тыю билгеләү | әйе/юк | әйе |
| 3. | Җирле үзидарә органнары, бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең кабатлаучы функцияләрен анализлау | әйе/юк | әйе |
| 4. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең саны 1 педагогик хезмәткәргә исәпләгәндә (кеше) | $U = N_v / N_{pd}$, где $N_v$ –тәрбияләнүчеләр саны; $N_{pd}$ - педагогик хезмәткәрләр саны | 8,8дән ким түгел |
| 5. | 1 педагогик хезмәткәргә исәпләгәндә укучылар саны (кеше) | $U_p = N_o / N_{po}$, где $N_o$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны; $N_{po}$ - гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре саны | 11,8дән ким түгел |
| 6. | 1 мәдәният учреждениесе хезмәткәренә туры килгән хезмәт алучылар саны (исемлек буенча уртача саны буенча) (кеше) | $H_n = N_{pl} / N_w$, монда $N_{pl}$ - мәдәният учреждениеләре күрсәтә торган хезмәтләрне алучылар саны; $N_w$ - мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны | 138дән ким түгел |
| 7. | Товарлар, эшләр, хезмәт | $O_n = A_{pl} / B_w$, | 75%тан ким |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күрсәтүләр сатып алуларның гомуми суммасында электрон конкурент сатып алуларның өлеше, % | монда $A_{pl}$ - электрон формада үткәрелгән сатып алуларның суммар бәясе; $B_w$ - үткәрелгән сатып алуларның бөтен бәясе | түгел |
| 8. | Кулланыла торган салым ташламаларына мониторинг үткәрү | әйе/юк | әйе |
| 9. | Узган елның салым һәм салым булмаган керемнәр күләменә бюджетка түләүләр буенча недоимканың чагыштырмасы, % | $К= D_{pl}/ C_{p-1}+ T_{p-1}$,<br>монда $D_{pl}$ - хисап елы өчен недоимка суммасы;<br>$C_{p-1}+ T_{p-1}$ - узган елгы салым һәм салым булмаган керемнәр күләме суммасы | 6%тан артык түгел |

## 5. Программа чаралары

5.1. Программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

а) җирле үзидарә органнарын тоту чыгымнарын оптимальләштерү - Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органнарында чыгымнарны агымдагы тотуга оптимальләштерүгә юнәлдерелгән муниципаль идарә өлкәсендәге чаралар;

б) бюджет челтәрен тотуга чыгымнарны, шулай ук бюджет даирәсендә эшләүчеләр санын оптимальләштерү - муниципаль учреждениеләр тотуга чыгымнарның нәтиҗәсезлеген киметүгә юнәлдерелгән бюджет челтәре белән идарә итү чаралары;

в) конкурс процедураларыннан файдаланып, муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алулар күләмен арттыру - сатып алулар өлкәсендә нәтиҗәле идарәгә юнәлдерелгән чаралар;

г) салым һәм салым булмаган керемнәр буенча бурычларны кыскарту, өстәмә, шул исәптән бюджеттан тыш чыганакларны табу.

5.2. 2020 елга Зәй муниципаль районы бюджетының өстәмә керем чыганакларын эзләү, бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, акчаларны экономияле тоту, түләүләр буенча бурычларны киметү буенча чаралар исемлеге Программаның 1 кушымтасында тәкъдим ителә.

Короновирус инфекциясе таралу белән бәйле икътисади вәзгыятьнең үзгәрүе бюджетның керем өлешен тулыландыруны чикли, район тормышының агымдагы мәсьәләләрен хәл итү һәм приоритетларны

тормышка ашыру өчен кирәкле өстәмә чыганаклар эзләүдә җирле үзидарә органнарының үз вакытында илтифат итүен таләп итә.

Алдагы еллардагы кебек үк, сатып алуларның конкурентлы төрләрен, беренче чиратта, ачык электрон аукцион формасын куллану күздә тотыла.

Социаль-икътисадый үсешнең заманча тенденцияләрен, шулай ук агымдагы икътисадый шартларда Зәй муниципаль районы бюджетын үтәү практикасын исәпкә алып, муниципалитетның финанс тотрыклылыгын арттыру максатларында муниципаль финанслар белән идарә итү механизмнарын камилләштерү эшен дәвам итү актуаль булып кала.

Килеп туган чынбарлыкны исәпкә алып, район бюджеты чыгымнарын булган финанс мөмкинлекләренә туры китерү зарурлыгы бар, бу исә бюджет чаралары белән идарә итүгә, бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген һәм рациональлеген күтәрүгә аерым игътибар бирүне таләп итә.

Районның тотрыклы үсешен тәэмин итү өчен керемнәрне мобилизацияләү, чыгымнарның җайлашучанлыгын арттыру, резервларны ачыклау, өстенлекле юнәлешләр һәм проектлар файдасына ресурсларны яңадан бүлүгә юнәлдерелгән чаралар (1 кушымта) үткәрү планлаштырыла.

Җирле салымнар, җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын легальләштерү өчен, теркәүгә алынмаган күчемсез милек объектларын, җир кишәрлекләрен ачыклау һәм аларны Росреестр органнарында теркәү һәм салым органнарында исәпкә кую буенча чаралар күреләчәк.

Дәүләт адреслы реестры, күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматларын тулыландыру һәм актуальләштерү буенча системалы эш дәвам итәчәк.

Салым булмаган керемнәрнең тотрыклы үсешенә ирешү максатларында мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә чаралар комплексын гамәлгә ашыру планлаштырыла.

Эш түбәндәге юнәлешләр буенча дәвам итәчәк:

- муниципаль мөлкәттән нәтиҗәле файдалану ысулларын билгеләү максатларында, муниципаль мөлкәттән фактта файдалануны инвентарьлаштыру һәм анализлау, шул исәптән хосусыйлаштыруның фаразлау планына кертү;
- аукционнардан сату өчен җир кишәрлекләре буенча резервларны ачыклау;
- файдаланылмый торган җирләрне, муниципаль милектәге билгеләнеше буенча файдаланылмый торган җирләрне ачыклау буенча контроль чаралар уздыру, алга таба ачык сатулар аша аренда хокукын гамәлгә ашыру максатыннан;

- алга таба хуҗалык әйләнешенә кертү максатларында, хуҗасыз объектларны ачыклап, аларны муниципаль милеккә рәсмиләштерү;

- район территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре төзүгә хокук сату буенча аукционнарда катнашуга потенциаль сатып алучыларның киң даирәсен җәлеп итү максатыннан, реклама-мәгълүмати кампания үткәрү.

Салым булмаган керемнәрне арттыру өчен резерв булып аренда түләүләре буенча бурыч торуын исәпкә алып, федераль законнарда каралган бурычларны түләттерүченең хокукларын гамәлгә ашыру максатларында бурычларны түләтү чараларын системалы куллану дәвам итәчәк.

Район бюджетының керем базасын тулыландыру буенча куелган бурычларны тормышка ашырганда, үз керем базасын киңәйтү мөмкинлекләре чикләнгән булуны исәпкә алырга кирәк.

Муниципаль милек белән эш итүдән кергән керемнәр бетә. Казнадагы калган объектлар бизнес вәкилләрен базар ягыннан кызыксындырырлык түгел һәм еш кына начар техник хәлдә.

Район бюджетының үз керем базасы чикләнгән шартларда өстәмә керемнәрне җәлеп итү эше аеруча актуаль булып кала. Моның өчен барлык җирле үзидарә органнары алдына федераль һәм республика программаларын һәм проектларын муниципалитетның аларда катнашу мөмкинлеге буенча анализлау бурычы куела.

## 6. Хәвефлелекне бәяләү, аларны киметү чаралары

Муниципаль программаны гамәлгә ашырганда хәвефлелек куркынычларын, аларның барлыкка килү сәбәпләрен һәм аларны минимальләштерү чараларын анализлау таблицада китерелгән:

| Хәвефлелек, куркынычның исеме | Барлыкка килү сәбәпләрен анализлау | Аларны киметү буенча чаралар |
|---|---|---|
| 1.Идарә итү хәвефлелеге | Идарә итү персоналының тәҗрибәсе җитәрлек булмау | Финанс хәле һәм хокукый хәл, программада катнашучылар эшчәнлегенең башка аспектлары мониторингын оештыру |
| 2. Икътисади финанс куркынычлары | Финанс куркынычы барлыкка килүгә этәргеч бирә:<br><br>-икътисади | Планнар, проектлар эшләүдә, законнар таләпләренә туры килә торган нигезләмәләр, бәяләмәләр әзерләүдә |

| | | |
|---|---|---|
| | тотрыксызлык;<br><br>- бюджет акчалары кытлыгы;<br><br>- базарда ресурслар бәясенең артуы | ярдәм күрсәтү. |
| 3. Программада катнашучыларның эшчәнлеген җайга сала торган норматив хокукый законнарны үзгәртү куркынычы | Муниципаль программага үзгәрешләр кертү | Норматив документлар нигезендә чараларны гамәлгә ашыру |

**7. Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре**

7.1. Программаны тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:

- Зәй муниципаль районы муниципаль финансларының торышын яхшырту механизмнарын активлаштырырга;
- Зәй муниципаль районы бюджетының тотрыклы үтәлешен тәэмин итү һәм бюджетның баланслылыгын тәэмин итү өчен шартлар тудыруга;
- муниципаль идарә чыгымнарын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыруга;
- Зәй муниципаль районының финанс һәм бюджет өлкәләрендә социаль-икътисади үсеш күрсәткечләрен яхшыртырга;
- бюджет акчаларын сарыф итү нәтиҗәлелеген арттырырга.

**8. Программа белән идарә итүне оештыру**

8.1. Программа белән идарә итү Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасы тарафыннан башкарыла.

8.2. Җирле үзидарә органнары (алга таба - ОМСУ), Зәй муниципаль районы бюджет акчаларын баш бүлүчеләр (алга таба - ГРБС) программа чараларын тормышка ашыруда катнашалар.

8.3. Программаны тормышка ашыру механизмы үз эченә ала:

- программа максатларына һәм бурычларына ирешү өчен Зәй муниципаль районы бюджеты акчаларын куллануның нәтиҗәле ысулларын эшләү;
- ситуацияне анализлау, уңай тәҗрибәне гомумиләштерү максатында бюджет өлкәсендә үзгәрешләрне квартал саен мониторинглауны тәэмин итү;
- программа чараларын башкаручыларның эшчәнлеген координацияләү.

8.4. Җирле үзидарә органнары, Зәй муниципаль районы бюджет акчаларын баш бүлүчеләр хисап чорыннан соң килгән айның 15 числосыннан

да соңга калмыйча Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасына тапшыралар:

- Зәй муниципаль районының 2020 елга бюджет чыгымнарын оптимальләштерү буенча чаралар исемлеген үтәүнең барышы турында хисап (2 кушымта).

- программага кертү өчен тәкъдим ителгән төзәтмәләр һәм өстәмәләр буенча тәкъдимнәр.

8.5. Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасы җирле үзидарә органнары, Зәй муниципаль районы бюджет акчаларын баш бүлүчеләр тәкъдимнәре нигезендә программага үзгәрешләр кертү турында Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары проектын әзерли.

**Бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, Зәй муниципаль районының өстәмә керем чыганакларын эзләү чаралары ИСЕМЛЕГЕ**

| | чараның исеме | җаваплы башкаручылар | гамәлгә ашыру вакыты | үлчәү берәмлеге | максатчан күрсәткечнең әһәмияте |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2020 ел |
| **1.** | **Салым һәм салым булмаган кертемнәр керемнәрен арттыру чаралары** | | | | |
| 1.1. | Салым һәм җыемнар буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган салым ташламаларының нәтиҗәлелеген бәяләү, алга таба нәтиҗәсез ташламаларны юкка чыгару һәм бирү критерийларын катгыйландыру / | Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 01.11.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |
| 1.2. | Җирле салымнар һәм җыемнар буенча ставкаларны яңадан карау | Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 01.11.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |
| 1.3. | Зәй муниципаль районы территориясендә салым исәбенә куймыйча эшчәнлек алып баручы аерымланган бүлекчәләрне ачыклау. Эш урыннары урнашкан урын буенча аерымланган бүлекчәләрне салым исәбенә кую буенча чаралар үткәрү | Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | 170,0 |
| 1.4. | Күләгәдәге мәшгульлекне легальләштерү чараларын үткәрү | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты | ай саен | мең сум | 50,0 |
| 1.5. | Салым булмаган керемнәр күләмен арттыру, шул исәптән муниципаль берәмлекләр мөлкәте һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләре, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре арендага тапшырыла торган аренда түләвенең нәтиҗәле ставкаларын билгеләү чараларын үткәрү исәбенә.<br>Муниципаль милектәге мөлкәтне инвентарьлаштыруны дәвам итәргә:<br>-муниципаль мөлкәтнең тотальь исәбен кертергә<br>- файдаланылмаган (хуҗасыз) урынны ачыклау һәм аннан нәтиҗәле файдалануны билгеләү;<br>- арендага бирелә торган мөлкәт исемлеген арендага түләү рәвешендә алына торган керемнәрне яисә вакытлыча биләүгә һәм файдалануга тапшырган өчен башка түләүне арттыру максатында билгеләү һәм раслау;<br>- муниципаль учреждениеләрнең файдаланылмый торган төп фондларын ачыклау һәм аларны сату | Зәй муниципаль районы башкарма комитеты, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |
| 1.6. | Вовлечение в налоговый оборот объектов недвижимости, включая земельные участки, в том числе: уточнение сведений об объектах недвижимости; актуализация результатов государственной кадастровой оценки объектов недвижимости; предоставление сведений о земельных участках и иных объектах недвижимости в рамках информационного обмена; проведение муниципального земельного контроля. Выявление собственников земельных участков и другого недвижимого имущества и привлечения их к налогообложению, содействие в оформлении прав собственности на земельные участки и имущество физическими лицами. | Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты, финанс инспекторлары | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |

| | чараның исеме | җаваплы башкаручылар | гамәлгә ашыру вакыты | үлчәү берәмлеге | максатчан күрсәткечнең әһәмияте |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2020 ел |
| 1.7. | Физик затларның милек салымнарын мобилизацияләү буенча чаралар үткәрү | Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |
| 1.8. | Салым түләүләре буенча Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына бурычларны кыскарту чараларын үткәрү | Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | бюджетный эффект |
| **2.** | **Чыгымнарны оптимальләштерү чаралары** | | | | |
| **2.1.** | **Идарә органнары чыгымнарын оптимальләштерү** | | | | |
| 2.1.1. | Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре санын арттыруга юл куймау | Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 31.12.2020 елга кадәр | % | 100 |
| 2.1.2. | Җирле үзидарә органнарын тотуга чыгымнарны киметү | Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |
| **2.2.** | **Бюджет челтәрен оптимальләштерү** | | | | |
| 2.2.1. | Зәй муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең берләштерелгән бюджетларының чыгымнарын оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү | Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр | 2020 ел дәвамында | мең сум | 3455,3 |
| 2.2.2. | Аерым муниципаль программаларны, проектларны туктатып тору һәм финанс чараларын өстенлекле муниципаль программаларга, проектларга бүлү турында тәкъдимнәр әзерләү | Башкарма комитет | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | 130,0 |
| 2.2.3. | Бюджет һәм автоном учреждениеләрнең бюджеттан тыш эшчәнлегеннән керемнәр исәбеннән чыгымнар күләмен арттыру | Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр | 2020 ел дәвамында | мең сум | бюджет эффекты |
| 2.2.4. | Бюджет өлкәсендә муниципаль учреждениеләр челтәрен аларны бетерү яисә башка оештыру-хокукый рәвешкә үзгәртү юлы белән оптимальләштерү | Исполнительные комитеты города и сельских поселений, МКУ | до 1.09.2020 | мең сум | 1 406,7 |
| 2.2.5. | Учреждениеләрнең артык мөлкәтен сату, консервацияләү | Главные распорядители бюджетных средств, МБУ, ПИЗО | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | 618,0 |

| | чараның исеме | җаваплы башкаручылар | гамәлгә ашыру вакыты | үлчәү берәмлеге | максатчан күрсәткечнең әһәмияте |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2020 ел |
| 2.2.6. | Коммуналь хезмәтләрне экономияле куллану буенча чараларны тормышка ашыру | Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр | квартал саен | мең сум | бюджет эффекты |
| 2.2.7. | Муниципаль сатып алуларның конкурентлы формалары күләмен арттыру | Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр | квартал саен | мең сум | бюджет эффекты |
| **2.3.** | **Инвестиция чыгымнарын оптимальләштерү** | | | | |
| 2.3.1. | Муниципаль дәрәҗәдә бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга бюджет чыгымнарын оптимальләштерү (капиталь кертемнәрне югары әзерлекле объектларга гына кертү, финанслауның мәҗбүри күләмен тәэмин итү мөмкинлекләрен исәпкә алып, элек башланган төзелешне төгәлләүнең максатчанлыгына анализ ясау) | Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |
| 2.3.2. | Төгәлләнмәгән төзелеш күләмнәрен кыскарту | башкарма комитет | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |
| **2.4.** | **Дебитор һәм кредит бурычларын киметү** | | | | |
| 2.4.1. | Финанс елы йомгаклары буенча Зәй муниципаль районының казна, бюджет һәм автоном учреждениеләренең вакыты чыккан кредитор бурычлары булмавын тәэмин итү | Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |
| 2.4.2. | Агымдагы кредиторлык һәм дебиторлык бурычы барлыкка килү сәбәпләрен анализлау | Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр | 31.12.2020 елга кадәр | мең сум | бюджет эффекты |

Примечание: бюджетный эффект на 2020 год рассчитывается как отклонение от фактических показателей 2019 года.

2 кушымта

**2020елның ___________ өчен бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, өстәмә керем чыганакларын эзләү чараларын гамәлгә ашыру турында хисап**

---

*(җирле үзидарә органы, бюджет средстволарын баш бүлүчеләрнең исеме)*

| № п/п | Программага кушымта нигезендә чараның исеме | Бюджет эффекты, мең сумнарда | | | Башкару турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Факт 2019 елга | Хисап елына план | Фактта башкару 01.07.2020 елга | |
| | | | | | |
| | | | | | |